РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.07.2023 Кукмара ш. №421

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2019 елның 07 ноябрендәге 617 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тукландыруны оештыру тәртибе турында» Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясындагы 7.2 өлеше, «Мәгариф турында» 2013 елның 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 6.1 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына укучыларның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм күрсәтү чаралары бирү максатларында **карар бирәм**:

1. Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2019 елның 07 ноябрендәге 617 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тукландыруны оештыру тәртибе турында» Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- өйдә гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны (ОВЗ), азык-төлек җыелмасы биреп яисә бушлай ике тапкыр туклануны һәм азык-төлек җыелмасын айга бер тапкыр акчалата компенсация белән алыштырып, ике тапкыр бушлай кайнар туклану белән тәэмин итү:

– көненә бер балага иртәнге аш – 8 сум 80 тиен, төшке аш – 37 сум.».

2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларына, әлеге карарның 1 пункты нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, Нигезләмәне гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Х. Гарифуллин**